ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 16 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 20 августында
кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» 2010 елның 2 августындагы 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 8 – 9; 2012, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 22 (I өлеш); 2019, № 40 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 3^1 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«3^1) региональ инновацион үсеш институтлары эшчәнлеген координацияләүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарын күрсәтеп, мондый институтларның исемлеген раслый;».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 04 сентябрь
№ 49-ТРЗ